СОВЕТ СТАРОЧУРИЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ АРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ АРЧА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИСКЕ ЧҮРИЛЕ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

ул. Новая, д.52, с. Старое Чурилино, Арский муниципальный район, 422014

Яңа урамы, 52 нче йорт, Иске Чүриле авылы, Арча муниципаль районы, 422014

Тел. (84366)57-3-48, 3-06-09 факс (84366)57-3-48, 3-06-09 E-mail: Schur.Ars@tatar.ru.

**Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы**

# КАРАРЫ

**30 октябрь 2023 ел** **№ 5**

## Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Татар Кәдрәге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Уставының 25 статьясы нигезендә, Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Башлыгы Карар бирде:

1. Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Татар Кәдрәге авылында, Ашабаш авылы, Комсомол урамы, 4А йорт адресы буенча гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча 2023 елның 15 ноябренә 17 сәгать 00 минутта халык җыены билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарылучы түбәндәге мәсьәләне расларга:

«Сез 2024 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Иске Чүриле авыл җирлеге Татар Кәдрәге авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 200 сум тәшкил иткән көндезге формада укучы студентлардан, хәрби хәрәкәтләрдә катнашучылардан, 70 яшьтән узган гражданнардан тыш, 400 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

- Җирле әһәмияткә ия булган машина юлына вак таш җәеп, юл полотносын ремонлау, Татар Кәдрәге авылы, Аркылы урамы 11 йорттан 13 йортка кадәр?

«ӘЙЕ» «КАРШЫ»»

3. Арча муниципаль районы районы Иске Чүриле авыл җирлеге Татар Кәдрәге авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы итеп Иске Чүриле авыл җирлеге башкарма комитетын билгеләргә.

4. Әлеге карарны халык күп җыела торган урыннарда мәгълүмат стендларына ТР, Арча районы Татар Кәдрәге авылы, Аркылы урамы, 17 йорт адресы буенча, интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Арча муниципаль районының рәсми сайтында http://arsk.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә һәм Татарстан Республикасы Рәсми хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Иске Чүриле авыл җирлеге
башлыгы урынбасары — И.Н. Габдрахманов